ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында

Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Д.Д. Натфуллин докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2026 елда күренекле татар шагыйре, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлиловның) тууына 120 ел тулуга багышланган чараларны әзерләү һәм үткәрү максатларында 2026 елның 16 гыйнварындагы 26-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән төзелгән оештыру комитеты эшен координацияләүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы Милли музее белән берлектә Муса Җәлилнең музей-фатиры – Татарстан Республикасы Милли музее филиалы эшчәнлеген камилләштерү, аудиторияне җәлеп итү һәм киңәйтү максатларында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Муса Җәлилнең музей-фатиры сайтын даими яңартып тору эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән берлектә ел дәвамында Муса Җәлилнең музей-фатирына һәм Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында оештырылган күргәзмә проектларына мәгариф оешмалары укытучыларының һәм белем алучыларының килүен оештыруны тәкъдим итәргә.
5. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итүне

әзерләүне һәм үткәрүне киң мәгълүмати яктыртуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында үткәрелә торган чараларда катнашуны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 13 феврале
№ 145-VII ДСП